| Республика Татарстан<br>Глава Верхне-Черцилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Югары<br>Чыршылы авыл җирлеге<br>башлыгы |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2025 № 8

2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартында “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Югары Чыршылы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 09.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында 2026 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Түбән Чыршылы торак пункты, Горький урамы, 9 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Чыршылы торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча йөртүче эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү); (Түбән Чыршылы торак пунктында җирлек юлы эчендә ремонтлау (ташу, вак таш салу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясен чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү): трактор тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу); Түбән Чыршылы торак пунктында);

3) Түбән Чыршылы торак пунктындагы урамнарны яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Сарман муниципаль районы Югары Чыршыды авыл җирлеге башлыгының «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 31.10.2025 ел, № 5 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Гилева